| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2023 г.Лениногорск № 52

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 30.07.2015 № 51, 30.03.2016 № 51, 27.12.2016 № 114, 30.05.2017 № 38, 08.08.2017 № 63, 15.11.2017 № 81, 19.01.2018 № 5, 29.03.2018 № 18, 27.09.2018 № 56, 13.12.2018 № 80, 06.02.2019 № 4, 23.10.2019 № 56, 21.02.2020 № 11, 12.11.2020 № 33, 26.03.2021 № 10, 06.08.2021 № 45, 20.05.2022 № 28, 03.03.2023 № 8, 10.08.2023 №41 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8.2.3, 8.3.1 пунктларда «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.»;

9.5 пунктта «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

9 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 9.5.1 пункт өстәргә:

«9.5.1. Муниципаль хезмәткәрләргә 9.5 пунктында күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

19 нчы бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 19.4.15 пункты белән тулыландырырга:

«19.4.15.Муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын

булдырмау яки җайга салу таләпләрен һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләр, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар нәтиҗәсе булып таныла икән, җаваплылыктан азат ителә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары С.В. Тимаковка йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов